**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2017-2018 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл - 100**

## I. Теоретик биремнәр (35 балл).

1. Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләрнең төрен һәм жанрын билгеләгез (20 балл):

*“Идегәй”* ***–поэзия яки лиро-эпик төр, дастан,***

*М.Әгъләмов “Җил дә җил”* ***–поэзия яки лирик төр, гражданлык лирикасы яки шигырь***

*Г.Бәширов “Туган ягым – яшел бишек”* ***–эпик төр яки проза, авторбиографик повесть***

*Г.Камал “Беренче театр”* ***–драма төре, комедия***

*Ф.Кәрим “Сибәли дә сибәли”* ***–поэзия яки лирик төр, күңел лирикасы яки шигырь***

2 Әлеге билгеләмәләрдән пейзаж төшенчәсенә туры килгәнен сайлап алыгыз (7 балл):

***1) әсәрләрдә табигать күренешләренең бирелешен ачыклый торган теоретик төшенчә;***

*2) геройның тышкы кыяфәтенең бирелеше;*

*3) әсәрдә табигать образлары ярдәмендә геройның күңел кичерешләрен тасвирлау;*

*4) әсәрдәге вакыйгаларның бара торган урынын сурәтләү.*

3. М.Әгъләмовның “Җил дә җил” шигырендә җил образы кайсы теоретик төшенчәгә туры килә (8 балл):

*А) юллар җыры*

*Б)* ***Символ***

*В) Пейзаж*

*Г) метафора.*

## II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (45 балл).

1. Т.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” әсәрендә Әлмәндәр белән Әҗәл тартышы ничек тәмамлана? ***Әлмәндәр үз теләге белән үлем кәгазенә кул куя, Әҗәл аны Газраил янына алып килә, Әлмәндәр фәрештәләр белән шаяртып йөри*** (5 балл)

2. Әлмәндәр “*син дә берүзең чишмәгә килгәнсең ич. Төн дип тормагансың*”, – дип, кемгә мөрәҗәгать итә? (10 балл) ***Йөзембикә***

3. “Әлдермештән Әлмәндәр” әсәрендә Т.Миңнуллин Әлмәндәр һәм Әҗәл образлары ярдәмендә нинди мәңгелек төшенчәләр турында сөйли? Үз фикерегезне дәлилләп бирегез (15 балл) ***Яшәү һәм үлем турында***

4. Ни өчен әсәр бүген дә актуальлеген югалтмаган дип уйлыйсыз? (15 балл) ***Әсәр үлемсез төшенчәләр турында сөйли, бай күңелле Әлмәндәр карт турында яза, кешеләрне оптимист, матур күңелле булырга өнди һ.б.***

**III. Иҗади бирем (20 балл).**

1. Күңел матурлыгы турында кечкенә генә хикәя языгыз.